ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.04.2015 ел Казан №6-26/тп

***“Алабуга су каналы” МУПнең үзәкләштерелгән суны чыгару системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) тарифларын билгеләү турында***

“Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында” 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, “Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында” 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, “Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында 2013 елның 29 июлендәге 644 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, “Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынучы тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турындагы” тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге № 1746-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китерепТатарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Алабуга су каналы” МУПнең үзәкләштерелгән суны чыгару системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) тарифларын әлеге карар кушымтасындагыча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт комитеты
карарына кушымта
17.04.2015 № 6-26/тп

“Алабуга су каналы” МУПнең үзәкләштерелгән суны
чыгару системасына тоташтыру
(технологик тоташтыру) тарифлары

| № | Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | Тоташтыруга тарифлар (НДСтан тыш) |
|---|---|---|---|
| 1. | Тоташтырылучы йөкләнешкә тарифның база ставкасы | Мең сум /тәүлеккә куб м. | 0,119 |
| 2. | Челтәрнең озынлыгына тарифның база ставкасы | Мең сум / км | 2 370,22 |
| 3. | Челтәрләр диаметрына бәйле тарифны дифферентлаштыру коэффициенты: | | |
| 3.1. | 40 мм һәм аннан кечерәк диаметрлы | - | - |
| 3.2. | 40 мм – 70 ммдан (кертеп) зуррак диаметрлы | - | - |
| 3.3. | 70 мм – 100 ммдан (кертеп) зуррак диаметрлы | - | - |
| 3.4. | 100 мм – 150 ммдан (кертеп) зуррак диаметрлы | - | 0,26 |
| 3.5. | 150 мм – 200 ммдан (кертеп) зуррак диаметрлы | - | 0,26 |
| 3.6. | 200 мм – 250 ммдан (кертеп) зуррак диаметрлы | - | 0,90 |
| 3.7. | 250 мм һәм аннан зуррак диаметрлы | - | - |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге